КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 июль г.Казань № 550

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 138 нче; 2018 ел, 2 апрель, 200 нче; 2018 ел, 5 июнь, 425 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә үсемлекчелек өлкәсендә, орлык бәрәңге, ачык грунт яшелчәләре һәм озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

4 нче пунктның өченче абзацында һәм 8 нче пунктның өченче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә затлы орлыкчылыкны үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

4 нче пунктның өченче абзацында һәм 7 нче пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә күпьеллык үсентеләр үстерүдә булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

4 нче пунктның өченче абзацында һәм 7 нче пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сөтле терлекчелектә продуктивлыкны арттыруга юнәлдерелгән, Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

4 нче пунктның өченче абзацында һәм 8 нче пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

4 нче пунктның өченче абзацында һәм 9 нчы пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сарык һәм кәҗәләрнең ана башларын саклау һәм үрчетү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

4 нче пунктның өченче абзацында һәм 6 нчы пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә агросәнәгать комплексы объектларын төзү һәм модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен, шулай ук техника һәм җиһазлар сатып алу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

5 нче пунктның өченче абзацында һәм 7 нче пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә культуртехника, урман агромелиорациясе һәм гидромелиорация чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

5 нче пунктның өченче абзацында һәм 7 нче пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Агросәнәгать комплексында инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

4 нче пунктның өченче абзацында һәм 11 нче пунктның «б» пунктчасындагы дүртенче абзацта «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Озак вакытлы, уртача вакытлы һәм кыска вакытлы кредитлар буенча процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

4 нче пунктның өченче абзацында һәм 11 нче пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы иминиятләве шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләү өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

5 нче пунктның өченче абзацында һәм 8 нче пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Эшләрен башлап җибәрүче фермерларга дәүләт ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган грантлар бирү тәртибендә:

3.3.1 нче пунктның икенче абзацында һәм 5.3.1 нче пунктның икенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган грантлар бирү тәртибендә:

3.3.1 нче пунктның икенче абзацында һәм 5.3.1 нче пунктның икенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган грантлар бирү тәртибендә:

3.3.1 нче пунктның өченче абзацында һәм 5.3.1 нче пунктның икенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.6 нчы пунктта «кимендә бер ел үткәннән соң» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.1 нче пунктның икенче абзацында «70,0» санын «35,0» санына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә үсемлекчелек һәм терлекчелек тармакларын үстерүнең максатчан күрсәткечләренә ирешүгә ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

4 нче пунктның өченче абзацында һәм 6 нчы пунктның дүртенче абзацында «үзгәртеп оештыру,» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин